КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1083

Татарстан Республикасы территориясендә физик затларга, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм эшмәкәрлек эшен башларга планлаштыручы гражданнарга хезмәт күрсәтүгә йөз тоткан хезмәт күрсәтү үзәкләрен һәм юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм эшмәкәрлек эшен башларга планлаштыручы гражданнарга хезмәт күрсәтүгә йөз тоткан күп функцияле үзәкләрне үстерү турында

Татарстан Республикасы территориясендә физик затларга, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм эшмәкәрлек эшен башларга планлаштыручы гражданнарга хезмәт күрсәтүгә йөз тоткан хезмәт күрсәтү үзәкләре (алга таба – Үзәкләр) һәм юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә һәм эшмәкәрлек эшен башларга планлаштыручы гражданнарга хезмәт күрсәтүгә йөз тоткан күп функцияле үзәкләр (алга таба – бизнес өчен күп функцияле үзәкләр) эшен оештыруның уңай тәҗрибәсен исәпкә алып, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең (алга таба – Кагыйдәләр) 36 пункты нигезләмәләрен тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Үзәкләр эшчәнлеген оештыру эшчәнлекләрен «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» Федераль закон нигезендә гамәлгә ашыручы кредит оешмаларында (партнер оешмаларда) «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе

филиалларының өстәмә тәрәзәләрен булдыру юлы белән һәм (яки) Кагыйдәләр белән билгеләнгән тәртип нигезендә Үзәкләр функцияләрен тормышка ашыруга эшчәнлекләрен «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» Федераль закон нигезендә гамәлгә ашыручы кредит оешмаларын (партнер оешмаларны) җәлеп итү юлы белән гамәлгә ашырыла;

бизнес өчен күп функцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтүче һәм Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Бюджетларына кече һәм урта эшмәкәрлеккә, крестьян (фермер) хуҗалыкларын да кертеп, дәүләт ярдәме күрсәтү өчен федераль бюджеттан субсидияләр бирелә торган Россия Федерациясе субъектларын конкурс нигезендә сайлап алу шартларын һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларга таләпләрне раслау турында» 2015 ел, 25 март, 167 нче боерыгы нигезендә эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмаларда «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең махсуслашкан тәрәзәләрен, офисларын яки зоналарын булдыру юлы белән гамәлгә ашырыла;

Үзәкләрдә һәм бизнес өчен күп функцияле үзәкләрдә күрсәтелүе оештырылган дәүләт, муниципаль һәм бүтән хезмәт күрсәтүләр исемлекләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

2. Карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

2018 елга Татарстан Республикасында Үзәкләр һәм бизнес өчен күп функцияле үзәкләр челтәрен үстерү буенча чаралар планы («юл картасы»);

Татарстан Республикасы Үзәкләрне һәм бизнес өчен күп функцияле үзәкләрне урнаштыру схемасы.

3. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгын Татарстан Республикасы территориясендә Үзәкләрне һәм бизнес өчен күп функцияле үзәкләрне үстерү проектын тормышка ашыру өчен җаваплы итеп билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин